**ГЛАВА БОЛЬШЕКОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422727, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Большие Ковали, ул. Клубная, д.8, оф.1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422727, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Олы Кавал авылы, Клуб ур.,8 йорт, 1 офис

Тел./факс: +7(84365) 74-7-90, e-mail: Bkoval.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**13 ноябрь 2024 ел** **№ 2**

**Биектау муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегенең Олы Кавал, Чуашлы авылларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районының Олы Кавал авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:
1.1. 2024 елның 8 декабрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Кавал авыл җирлегенең чуашлы торак пунктында 9 сәгать 00 минутка үткәрү урыны: Чуашлы СК адресы: Чуашлы авылы, Клубная ур., 23(клуб бинасы);
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
2.1. Чуашлы торак пунктында: "Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Олы Кавал авыл җирлегенең чуашлы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү.
«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

3. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:
3.1. 2024 елның 8 декабрендә 11 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Олы Кавалы авыл җирлегенең Олы Кавалы торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Олы Кавалы авылы, Клубная ур., 8 (клуб бинасы);
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
4.1. Олы Кавал торак пунктында: "Сез Татарстан Республикасы Биектау

муниципаль районы Олы Кавал авыл җирлегенең Олы Кавал торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салым кертүгә 500 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су җыю манарасын демонтажлау, урнаштыру һәм төзекләндерү)

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Олы Кавал авыл җирлеге башлыгы А.И.Файзрахманов